КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 831

2022 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны;

2022 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләмен.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе белән берлектә, туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучы өч яшькә кадәрге балаларны аларның категорияләре, яшьләре һәм алына торган продукция төрләре буенча аерым исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2020 ел, 3 сентябрь, 783 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 6 сентябрь, 831 нче
карары белән расланды

2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнар

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Түбәндәге яшьтәге балаларга норматив чыгымнар, 1 көнгә сум | | |
|---|---|---|---|
| | 0 айдан 6 айга кадәр | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 23,6 | 49,34 | 34,3 |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 94,4 | - | - |

___________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 6 сентябрь, 831 нче
карары белән расланды

2022 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Балалар-ның яше | Бер елга дәүләт эше күләме, бала-көн | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптация ләнгән сыек сөт катнашма сы | сөт | кефир | эремчек |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| «Татарстан Республика-сында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Рес-публикасы Законына ку-шымтада билгеләнгән җан башына уртача кере-ме Татарстан Республика-сында билгеләнә торган яшәү минимумы күләмен-нән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗә-сеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 698 610 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 3 037 165 | 3 037 165 | 3 037 165 | 3 037 165 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 11 152 940 | 11 152 940 | 11 152 940 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 24 455 | - | - | - |